РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АРТАШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

422069, Республика Татарстан, Сабинский район, д.Два поля Арташ, ул. Тукая, 61
тел. (84362) 44-7-15

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ АРТАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

422069, Татарстан Республикасы, Саба районы, Ике басу Арташ авылы, Тукай урамы, 61 йорт
тел. (84362) 44-7-15

e-mail: Art.sab@tatar.ru


ПОСТАНОВЛЕНИЕ — КАРАР

27.11.2024 — № 39

Саба муниципаль районы Арташ авыл җирлеге Башкарма комитетының 25.01.2022 №3 карары белән расланган торак урыннарына мохтаҗ буларак гражданнарны исәпкә алу буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

РФ Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында»15.08.2022 №1415 карары нигезендә, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Арташ авыл җирлеге Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Саба муниципаль районы Арташ авыл җирлеге Башкарма комитетының «Торак урыннарга мохтаҗ буларак гражданнарны исәпкә алу буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 25.01.2022 елгы №3 карары белән расланган торак урыннарга мохтаҗ буларак гражданнарны исәпкә алу буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3.3.2.1 пунктының унберенче абзацы. түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Төзелгән гаризаны формат-логик тикшерү гаризаның электрон рәвешендәге һәр кырын тутыру барышында орган билгели торган таләпләр нигезендә Бердәм портал тарафыннан автомат рәвештә гамәлгә ашырыла. Бердәм портал гаризаның электрон рәвешендәге дөрес тутырылмаган кырын ачыклаганда, мөрәҗәгать итүчегә ачыкланган хатаның характеры һәм аны бетерү тәртибе турында гаризаның электрон рәвешендәге мәгълүмати хәбәр аша хәбәр ителә.»;

1.2. 2.6.1 пунктның 10), 15), 17), 18) пунктчаларында «Россия Федерациясе Пенсия фонды» сүзләрен «Россия Федерациясе пенсия һәм социаль иминият Фонды» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча, Саба муниципаль районының Арташ авыл җирлегенең рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/artash адресы буенча бастырып чыгарырга һәм җирлекнең мәгълүмати стендларында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Арташ авыл җирлеге Башлыгы — Р.И.Мөхәрләмов